КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 сентябрь г.Казань № 1128

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2019 ел, 2 июль, 546 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 2 март, 112 нче, 2022 ел, 5 февраль, 92 нче, 2023 ел, 7 сентябрь, 1092 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткечен исәпләү тәртибе»;

Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткечен исәпләү тәртибен өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 02 июль, 546 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 14 сентябрь, 1128 нче
карары редакциясендә)

# Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткечен исәпләү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнарның күрсәткечен исәпләү тәртибе мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнарның күрсәткечен билгеләү кагыйдәләрен билгели.

1.2. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеме белән бәйле норматив чыгымнарның күрсәткече чираттагы финанс елына һәм план чорына бер тәрбияләнүчегә исәпләгәндә билгеләнә.

## II. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткечен исәпләү тәртибе

2.1. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткече түбәндәге фомула буенча исәпләнелә:$R_{dpop}$),

$$R_{dpop} = \frac{(\frac{N_{ped}}{m_{lim}} \times C_{dpop} + (C_t + C_p + C_s))}{m_r},$$

монда:

$N_{ped}$ - мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында җитәкчеләрнең һәм педагогик хезмәткәрләрнең планлаштырыла торган саны;

$m_{lim}$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү буенча төркемнәрнең норматив тулылыгы;

$C_{dpop}$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын

формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү программасының уртача бәясе;

$C_t$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, квалификация күтәрү урынына барып җитүгә транспорт хезмәтләренең уртача бәясе;

$C_p$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, өстәмә һөнәри белем алу вакытына яшәүнең уртача бәясе;

$C_s$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, тәүлеклек чыгымнарның уртача бәясе;

$m_r$ - мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең гомуми саны.

2.2. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткечен исәпләгәндә кулланыла:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан агымдагы елның 1 сентябренә чираттагы финанс елына һәм план чорына торышы буенча мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында җитәкчеләрнең һәм педагогик хезмәткәрләрнең саны;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан агымдагы елның 1 сентябренә чираттагы финанс елына һәм план чорына торышы буенча мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләр саны планлаштырыла.

2.3. Җитәкчеләрнең һәм педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белеме, бер белем бирү программасына бәйле чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:$R_{dpop_y}$)

$$R_{dpop_y} = \frac{C_{dpop} + C_t + C_p + C_s}{m_{lim}} ,$$

монда:

$C_{dpop}$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү программасының уртача бәясе;

$C_t$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, квалификация күтәрү урынына барып җитүгә транспорт хезмәтләренең уртача бәясе;

$C_p$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, өстәмә һөнәри белем алу вакытына яшәүнең уртача бәясе;

$C_s$ - планлаштырыла торган чорга кадәрге елның 1 сентябренә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып, тәүлеклек чыгымнарның уртача бәясе;

$m_{lim}$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү буенча төркемнәрнең норматив тулылыгы.

2.4. Төгәл бер мәктәпкәчә белем бирү оешмасында (i) җитәкчеләрнең һәм педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белеме белән бәйле чыгымнар түбәндәге формула буенча исәпләнә:$R_{dpop_i}$)

$$R_{dpop_i} = R_{dpop} \times m_{r_i} - R_{dpop_y} \times N_{ped_i},$$

монда:

$R_{dpop}$ - мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һәм педагогик хезмәткәрләренең өстәмә һөнәри белеменә бәйле норматив чыгымнар күрсәткече;

$m_{r_i}$ - төгәл бер мәктәпкәчә белем бирү оешмасында (i) тәрбияләнүчеләр саны;

$R_{dpop_y}$ – җитәкчеләрнең һәм педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белеме белән бәйле программаның бер укучысына чыгымнар;

$N_{ped_i}$ - төгәл бер мәктәпкәчә белем бирү оешмасында (i) җитәкчеләр һәм педагогик хезмәткәрләр саны.

Төгәл бер мәктәпкәчә белем бирү оешмасында (i) җитәкчеләрнең һәм педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белеме белән бәйле чыгымнарның хисабы үзара субсидияләү принцибына нигезләнгән, шул ук вакытта исәп-хисап түбәндәге формулаларның берсе буенча тормышка ашырыла:$R_{dpop_i}$

әгәр $R_{dpop_i} \geq 0$, $R_{dpop_i} = R_{dpop_y} \times N_{ped_i}$ була;

әгәр $R_{dpop_i} < 0$, $R_{dpop_i} = R_{dpop} \times m_{r_i} + R_{dpop_y} \times N_{ped_i} - R_{dpop} \times m_{r_i}$) була.

2.5. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм педагогик хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программалары чараларын гамәлгә ашыруга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла.

_______________________